Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы
җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү боерыгы проекты буенча гавами тыңлаулар башлану турында хәбәр итү.

1. Татарстан Республикасы, Чистай муниципаль районы, Данауровка авыл җирлеге, авыл хуҗалыгы эшчәнлеге территориясе, 9 җир кишәрлеге, 33 111 кв. м. мәйданлы, 16:42:180207:288 кадастр номерлы җир кишәрлегеннән шартлы рәвештә файдалануга рөхсәт бирү боерыгы проекты буенча гавами тыңлаулар башлануы хакында хәбәр итәбез. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Данауровка авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең торак территориясе (п-2) чикләрендә урнашкан сәнәгать һәм коммуналь предприятиеләр зонасында" урнашкан авыл хуҗалыгы продукциясен саклау һәм эшкәртү (алга таба — проект).

2. Проектка мәгълүмати материаллар исемлеге:
- Гариза;
- Күчемсез мөлкәтнең дәүләт реестрыннан өземтә;
- Чистай муниципаль районының "Чистай шәһәре" муниципаль берәмлегенең 2024 елның 06 мартындагы 30/9 номерлы җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләреннән Схема.

3. Проект буенча гавами тыңлаулар үткәрү тәртибе һәм сроклары:
Проект буенча ачык тыңлаулар 2026 елның 03 июленнән 2026 елның 15 июленә кадәр уздырыла.
Гавами тыңлаулар үткәрү процедурасына түбәндәге этаплар керә:
- гавами тыңлаулар башлану турында хәбәр итү;
- проектны һәм аңа мәгълүмати материалларны рәсми сайтка урнаштыру һәм мондый проект экспозицияләрен ачу;
- проект экспозицияләрен үткәрү;
- гавами тыңлауларда катнашучыларның җыелышларын үткәрү;
- гавами тыңлаулар беркетмәсен әзерләү һәм рәсмиләштерү;
- гавами тыңлауларның нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү һәм бастырып чыгару.

4. Гавами тыңлауларда катнашучылар даирәсе:
Проект буенча гавами тыңлауларда катнашучылар булып:
- Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының "Чистай шәһәре" муниципаль берәмлеге территориясендә даими яшәүче гражданнар;
- Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының "Чистай шәһәре" муниципаль берәмлеге чикләрендәге җир кишәрлекләренең һәм (яисә) аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларының хокук ияләре;
- күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларының бер өлеше булган урыннарның хокук ияләре.

5. Гавами тыңлаулар уздырыла торган территория:
ТР, Чистай районы, Данауровка авылы, Центральная урамы, 20а йорт, авыл мәдәният йорты бинасы

6. Проект экспозициясен ачу урыны һәм датасы:

- 2026 елның 03 июлендә 14: 00 сәгатьтә, Чистай районы, Данауровка авылы, Центральная урамы, 20а йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасы.

7. Проект экспозицияләрен үткәрү сроклары:
2026 елның 03 июленнән 2026 елның 15 июленә кадәр.

8. Экспозицияләрне карарга мөмкин булган көннәр һәм сәгатьләр турында мәгълүмат:
Эш көннәрендә 09.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр, төшке аш тәнәфесе – 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр.

9. Гавами тыңлауларда катнашучыларның проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертү тәртибе, сроклары һәм рәвеше:
2026 елның 03 июленнән 2026 елның 14 июленә кадәр Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының (алга таба – РФ ГрК) $5^1$ маддәсенең 12 өлеше нигезендә идентификация узган гавами тыңлауларда катнашучылар проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертергә хокуклы:
- Чистай муниципаль районының рәсми сайты аша;
- Татарстан Республикасы Чистай шәһәр Башкарма комитетының (Архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге) гавами тыңлауларны оештыручыга түбәндәге адрес буенча: 422980, ТР, Чистай районы, Чистай шәһәре, К. Маркс урамы, 27 йорт, тел. (84342) 5-15-54 (9.00 дән 17.00 гә кадәр) язма яисә электрон документ рәвешендә бирергә хокуклы;
- ачык тыңлауларда каралырга тиешле проект экспозициясенә килүчеләрне исәпкә алу кенәгәсенә (журналына) язу юлы белән түбәндәге адрес буенча: 422980, ТР, Чистай районы, Чистай шәһәре, К. Маркс урамы, 27 йорт, тел. (84342) 5-15-54 (9.00 дән 17.00 гә кадәр).

Гавами тыңлауларда катнашучылар: РФ ГрК $5^1$ маддәсенең 12 өлеше нигезендә идентификация узган катнашучылар гавами тыңлауларда катнашучыларның җыелышларын үткәрү барышында тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне язмача яисә телдән кертергә хокуклы.

10. Гавами тыңлауларны үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында мәгълүмат:
проект буенча гавами тыңлауларны 2026 елның 15 июлендә уздырырга:
- ТР, Чистай районы, Данауровка авылы, Центральная урамы, 20а йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасына 14: 00 сәгатьтә.

11. Проект һәм аңа мәгълүмати материаллар урнаштырылачак рәсми сайт турында мәгълүмат:
Проект Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (chistopol.tatarstan.ru), 2026 елның 03 июленнән түбәндәге сылтама буенча: https://chistopol.tatarstan.ru/publichnie-slushaniya-847337.htm урнаштырылачак.

12. Әлеге хәбәрнамәне Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Чистай Башкарма комитеты
җитәкчесе урынбасары П. Б. Емельянов